КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 июль г.Казань № 794

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 924 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 924 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 818 нче, 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы, 2022 ел, 26 декабрь, 1417 нче, 2023 ел, 26 апрель, 527 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «бирелгән» сүзенә кадәр «2023 елда» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «бирелгән» сүзенә кадәр «2023 елда» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «бирелгән» сүзенә кадәр «2023 елда» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «бирү шартлары һәм механизмы» сүзләренә кадәр «2023 елда» сүзләрен өстәргә, «оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга» сүзләренә кадәр «махсус икътисадый зона төзү турындагы килешүдә махсус икътисадый зона инфраструктурасы объектлары буларак күрсәтелгән мөлкәткә карата 2022 елның узган салым чоры йомгаклары буенча» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия махсус икътисадый зона төзү турында килешүдә махсус икътисадый зона инфраструктурасы объектлары буларак күрсәтелгән мөлкәткә карата оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә юнәлдерелгән чыгымнар өлешен 2022 елның узган салым чоры йомгаклары буенча каплау максатларында бирелә.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге исемлек нигезендә документлар белән гариза тапшыра:

а) субсидия бирү турында гариза, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турында, сайлауда катнашучы тарафыннан бирелә торган, тиешле сайлап алуга бәйле башка мәгълүмат, Министрлык боерыгы белән расланган рәвештә сайлап алу белән бәйле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, аны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыкны үз эченә ала;

б) әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча, сайлап алуда катнашучы җитәкче һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган 2022 елның узган салым чоры йомгаклары буенча оешмалар мөлкәтенә салым исәпләү белешмәсе;

в) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым декларациясен, телекоммуникация элемтә каналлары буенча салым декларациясен җибәрүне һәм салым органы кабул итүне раслый торган квитанцияне һәм хәбәрнамәне;

г) «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән срокларда 2022 елның узган салым чоры йомгаклары буенча оешмалар мөлкәтенә салым түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләрен;

е) махсус икътисадый зона инфраструктурасы объектлары исемлеген билгели торган махсус икътисадый зона төзү турындагы килешүгә өстәмә килешү күчермәсен.

Сайлап алуда катнашучы Министрлыкка үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

гариза бирелә торган айның 1 көненнән дә иртәрәк булмаган датага бирелгән һәм һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

гариза бирелгән айга кадәрге айның 1 көненә карата сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан бу пунктның сигезенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Документлар кәгазь чыганакта бирелә. Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, моңа мөһер белән беркетелгән (булган очракта) һәм сайлап алуда катнашучының җитәкчесе имзасы белән таныкланган төзәтмәләр керми. Заявканың барлык битләре номерланган

булырга тиеш. Гариза тегелгән һәм, кәгазьләрнең гомуми саны күрсәтелеп, сайлап алуда катнашучының  имзасы һәм гаризаның икенче ягында мөһере (булганда) белән расланырга тиеш. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.»;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидия Россия Федерациясе Салым кодексы таләпләре нигезендә субсидия алучы тарафыннан түләнгән оешмалар мөлкәтенә салым суммасының бер өлеше күләмендә бирелә.

2022 елның узган салым чоры (C) нәтиҗәләре буенча субсидия суммасы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C= (B \times N) \times 0{,}99 - A,$$

монда:

B - әлеге Тәртипнең 10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә тапшырыла торган исәпләү белешмәсе һәм салым декларациясе мәгълүматлары нигезендә махсус икътисадый зона төзү турындагы килешүдә махсус икътисадый зона инфраструктурасы объектлары буларак күрсәтелгән мөлкәткә карата 2022 елның узган салым чоры йомгаклары буенча оешмалар мөлкәтенә салым базасы;

N - 2022 елның узган салым чорында гамәлдә булган оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым ставкасы;

A - 2022 елның узган салым чорының хисап чорлары өчен оешмалар мөлкәтенә салым буенча аванс түләүләрен түләүгә юнәлдерелгән чыгымнар өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан 2022 елда субсидия алучыга бирелгән субсидияләр суммасы.»;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

нумерация баш исемендә «бирелгән» сүзенә кадәр «2023 елда» сүзләрен өстәргә;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 елның узган салым чоры нәтиҗәләре буенча оешмалар мөлкәтенә салым исәпләү белешмәсе».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин